ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ҮЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

№ 1 2020 елның 28 гыйнвары

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Үзи авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең
гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган
хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Иске Үзи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 елның 1 февраленнән Аксубай муниципаль районының Иске Үзи авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6424,98 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын, 1 һәм 2 нче кушымталарга туры китереп, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2020 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карары 2021 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип санарга

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иске Үзи авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: Н. В. Айдова

Аксубай муниципаль районы
Иске Үзи авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2021 елның 28 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
1 нче кушымта

2021 елның 1 февраленнән
Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районының
Иске Үзи авыл җирлегендә җирләү буенча
хезмәтләрнең гарантияле исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү хакы (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2371,88 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 955,06 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 3098,04 |
| Барлыгы | **6424,98** |

Аксубай муниципаль районы
Иске Үзи авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2021 елның 28 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
2 нче кушымта

2021 елның 1 февраленнән
Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районының
Иске Үзи авыл җирлегендә җирләү буенча
хезмәтләрнең гарантияле исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү хакы (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетне кафенгә төрү | 409,00 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1962,88 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 955,06 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 3098,04 |
| Барлыгы | **6424,98** |